ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

16.11.2022

Казан ш.

**КАРАР**

№ 501-129/кс-2022

2023 елга «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык су агызуны хәл итүче «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» МУП) өчен, әлеге карар кушымтасы нигезендә эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне һәм су агызуны гамәлгә ашыручы «ТКХ (инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга

салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга 2022 елга тарифлар билгеләү хакында» 26.11.2021 №377-83/кс-2021, «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында» 09.02.2022 №9-3/кс-2022 карарларын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
16.11.2022 № 501-129/кс-2022
карарына кушымта

2023 елга салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу белән шөгыльләнүче
«ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» МУП өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүче оешма исеме | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | Әлмәт муниципаль районы | | |
| 1 | «ТКХ (Инженерлык челтәрләре)» МУП* | | |
| 1.1 | Рус Акташы һәм Урман-Кәләй авыл җирлекләрендәге кулланучылар өчен | 33,79 | 24,64 |
| 1.2 | Әлмәт, Аппак, Баграж-Никольский, Борискино, Бота, Васильевка, Югары Акташ, Югары Мактама, Елхово, Ерсубайкино, Кичү, Кичүчат, Клементейкино, Кузайкино, Колшәрип, Мәмәт, Миңлебай, Түбән Абдул, Яңа Кәшер, Яңа Нәдер, Яңа Никольский, Яңа Троицкий, Сәрән, Иске Михайловка, Иске Суркино, Сөләй, Ямаши, Ямаш авыл җирлекләре | 33,79 | |

<*> Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге